| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 25.12.2012** **№ 382**

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында информациядән файдаланучы гарызнамәсе буенча мәгълүмат бирүнең үрнәк тәртибен раслау турында**

“Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алуны тәэмин итү хакында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм «Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүмат бирү өчен түләү алу Кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карарын, шулай ук 2012 елның 8 декабрь 1068 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлеге турында мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучы гарызнамәсе буенча бирүнең үрнәк тәртибен раслау турында» Татарстан Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән БОЕРЫК БИРӘМ :

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында информаиядән файдаланучы гарызнамәсе буенча мәгълүмат бирүнең үрнәк Тәртибен (алга таба – Тәртип, Дәүләт комитеты) расларга.

2. Түбәндәге карар белән расланган Тәртипкә туры китереп, структур бүлекләр җитәкчеләре Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында информацияне бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземә йөклим.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына кушымта
25.12.2014 № 382

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында информаиядән файдаланучы
гарызнамәсе буенча мәгълүмат бирү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында информаиядән файдаланучы гарызнамәсе буенча мәгълүмат бирү тәртибе (алга таба – Тәртип, Дәүләт комитеты) «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алуны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм «Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүмат бирү өчен түләү алу Кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 860 номерлы карарын үтәү йөзеннән әзерләнде һәм Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучы гарызнамәсе буенча бирү процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатларында кулланылучы төп терминнар һәм билгеләмәләр:

1) Дәүләт комитеты эшчәнлеге турындагы мәгълүмат – Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында үз вәкаләтләре чикләрендә булдырылган мәгълүмат (белешмәләр) (шул исәптән документлаштырылган), яисә Дәүләт комитетына килгән (алга таба – мәгълүмат).

Дәүләт комитеты эшчәнлеге турындагы мәгълүматка шулай ук Дәүләт комитеты структурасын, вәкаләтләрен, аны формалаштыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен билгели торган закон актлары һәм башка норматив хокукый актлар керә;

2) мәгълүматтан файдаланучы – Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат эзләүче граждан (физик зат), оешма (юридик зат), дәүләт органы, җирле үзидарә органы, җәмәгать берләшмәсе;

3) гарызнамә – мәгълүматтан файдаланучының, Дәүләт комитеты эшчәнлеге турындагы мәгълүматны соратып, Дәүләт комитетына яисә аның вазыйфаи затына кергән телдән яки язма рәвештәге, шул исәптән электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгате.

2. Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча
мәгълүмат бирү тәртибе

2.1. Мәгълүматтан файдаланучы теләге буенча соратып алына торган мәгълүмат аңа телдән яисә документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул

исәптән кәгазь саклагычтагы документ рәвешендә почта аша яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге электрон документ рәвешендә, шулай ук гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре буенча бирелә.

2.2. Дәүләт комитетына язма рәвештә кергән гарызнамә, Дәүләт комитетының эш алып бару Инструкциясендә билгеләгән тәртиптә, кергән көненнән бер көн эчендә теркәлергә тиеш. Телдән әйтелгән гарызнамә кергән көнне үк, телдән әйтелгән гарызнамәләр журналында , керү датасы һәм вакыты күрсәтелеп, теркәлергә тиеш.

Дәүләт комитетына билгеләнгән эш көненнән соң һәм ял көннәрендә кергән гарызнамә, беренче эш көне датасы белән теркәлергә тиеш.

2.3. Гарызнамә, Татарстан Республикасы законнарында бүтәне каралмаган

булса, дәүләт комитеты тарафыннан теркәлгән көненнән утыз көн эчендә каралырга тиеш.

Соратып алына торган мәгълүматны күрсәтелгән срокта бирү мөмкин булмаган очракта, Дәүләт комитеты гарызнамә теркәлгән көннән җиде көн эчендә мәгълүматтан файдаланучыга, соңару сәбәбен һәм соратылучы мәгълүматны бирү срогын күрсәтеп, гарызнамәгә җавап соңрак биреләчәге турында мәгълүмат хәбәр итә, соңару әлеге Тәртип белән билгеләнгән сроктан унбиш көннән дә артык була алмый.

2.4. Дәүләт комитеты, мәгълүматтан файдаланучыга Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында кирәкле мәгълүматны бирү максатларында, гарызнамәнең эчтәлеген төгәлләштерергә хокуклы.

2.5. Мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучыга гарызнамәгә җавап рәвешендә бирелә, анда соратып алынучы мәгълүмат була яки аңа кушымта итеп бирелә, яисә анда әлеге Тәртипнең 2.11 пункты нигезендә мондый мәгълүматны бирүдән дәлилләнгән баш тарту була.

Гарызнамәгә җавапта Дәүләт комитеты исеме, почта адресы, җавапка имза салган затның Вазыйфасы, шулай ук гарызнамәгә җавап бирү реквизитлары (теркәлү номеры һәм датасы) күрсәтелә.

Гарызнамәгә җавап Дәүләт комитетында билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.6. Мәгълүмат мондый мәгълүмат бирү тәртибен регламентлый торган законнар нигезендә түләүсез яисә түләүле рәвештә аның күләменә, форматына бирелә, шул исәптән копиялар ясауга һәм (яисә) сорала торган документларны һәм материалларны җибәрүгә тотылган чыгымнарны кертеп.

2.7. Түләүсез нигездә мәгълүматтан файдаланучыга түбәндәге мәгълүмат

бирелә:

1) телдән бирелә торган;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге электрон документ рәвешендә, шулай ук Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүматны урнаштыру өчен билгеләнгән урыннарда бирелә торган;

3) мәгълүматтан файдалану белән кызыксынучы хокукларына һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән мәнфәгатьләренә кагылучы;

4) Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында законнар белән билгеләнгән башка мәгълүмат.

Әгәр дә мәгълүмат бирү өчен закон нигезендә түләү алынмаса, Дәүләт комитеты мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматны әлеге Тәртипнең 2.3-2.5 пунктларында каралган тәртиптә гарызнамә нигезендә бирә.

2.8. Әгәр дә мәгълүмат бирү өчен билгеләгән тәртиптә түләү алынырга тиеш булса[1], Дәүләт комитеты:

соралган мәгълүматнең күләмен һәм форматын күрсәтеп, шул исәптән түләү нигезендә тапшырыла торган мәгълүматнең күләмен күрсәтеп, түләүнең исәпләү тәртибен аңлатып, өстәмә чыгымнарны, түләү күләмен һәм түләү документларын тутыру өчен кирәк булган мәгълүматне күрсәтеп,гарызнамә теркәлгән көннән башлап, өч эш көне эчендә мәгълүматтан файдаланучыга гарызнамәдә күрсәтелгән адреска, хәбәр җибәрә;

түләүне раслаучы хәбәр алганнан соң, әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәткән вакыт эчендә, 2.5 пунктында күрсәтелгән тәртиптә, мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматне тапшыра.

2.9. Мәгълүматтан файдаланучы мәгълүматны кәгазь саклагычта йә компьютерда җыю җайланмасында турыдан-туры Дәүләт комитетында алырга теләгән очракта, Дәүләт комитеты әлеге Тәртипнең 2.8 пунктында каралган сроклар нигезендә гарызнамәгә җавапта өстәмә рәвештә мәгълүматтан файдаланучыга кирәкле мәгълүматны соратып алырга тиешле булган структур бүлекчә һәм аның вазыйфаи заты турында мәгълүмат бирә, анда структур бүлекчәнең адресы, телефоны, эш режимы яисә кабул итүнең төгәл датасы күрсәтелә, моңа өстәп җавапта шулай ук мәгълүматтан файдаланучыга Дәүләт комитетына махсус кертү режимы хакында хәбәр ителә.

Әгәр дә мәгълүмат бирү өчен түләү алынырга тиеш булса, соралган мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучы Дәүләт комитетында мәгълүмат бирү өчен җаваплы вазыйфаи затына түләү квитанциясен күрсәткәннән соң мәгълүматтан файдаланучыга тапшылыра.

2.10. Мәгълүматтан файдаланучыга төгәл булмаган белешмәләрдән торган мәгълүмат бирелгән очракта, Дәүләт комитеты мондый төгәлсезлекләрне мәгълүматтан файдаланучының дәлилләнгән язма гаризасы буенча, түләү алмыйча төзәтергә тиеш.

2.11. Дәүләт комитеты эшчәнлеге турындагы мәгълүматны бирү мөмкинлеген юкка чыгара торган нигезләр түбәндәгеләр:

1) гарызнамәнең эчтәлеге буенча Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында соратып алына торган мәгълүматны билгеләп булмау;

2) гарызнамәдә гарызнамәгә җавап җибәрү өчен почта адресы, электрон почта адресы яки факс номеры, яисә гарызнамә җибәргән мәгълүматтан файдаланучы белән элемтәгә керергә мөмкин булган телефон номеры күрсәтелмәү;

3) соратып алына торган мәгълүматның Дәүләт комитеты эшчәнлегенә кагылмау;

4) соратып алына торган мәгълүмат алу мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматлар рәтендә булуы;

5) соратып алына торган мәгълүмат элегрәк шул ук мәгълүматтан файдаланучыга бирелгән булу;

6) гарызнамәдә Дәүләт комитеты тарафыннан кабул ителгән актларга хокукый бәя бирү турындагы, аның эшчәнлегенә анализ ясау яисә гарызнамә

---

[1] Мәгълүмат бирү өчен түләү алу шартлары Россия Федерациясе 24.10.2011 № 860 карары белән расланган, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүмат бирү өчен түләү алу Кагыйдәләрендә билгеләнгән

җибәрүченең хокукларын яклауга турыдан-туры бәйле булмаган бүтән аналитик эш уздыру турындагы мәсьәлә куелу.

Дәүләт комитеты, үз эшчәнлеге турындагы мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган булса, гарызнамә буенча мәгълүматны бирмәскә дә хокуклы. Бу очракта гарызнамәгә җавабында Дәүләт комитеты соратып алына торган мәгълүмат бастырып чыгарылган массакүләм мәгълүмат чарасының исемен, чыгу датасын һәм номерын һәм (яисә) соратып алына торган мәгълүмат урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресын күрсәтү белән чикләнә.

2.12. Әгәр гарызнамә Дәүләт комитеты эшчәнлегенә карамаса, гарызнамә Идарәдә теркәлгән көннән җиде көн эчендә соратып алына торган мәгълүмат вәкаләтләренә карый торган дәүләт органына яисә җирле үзидарә органына җибәрелә. Гарызнамәне бүтән адреска җибәрү турында шул ук срокта гарызнамә җибәрүче мәгълүматтан файдаланучыга хәбәр ителә.

Дәүләт комитетының соратып алына торган мәгълүматның бүтән дәүләт органында яисә җирле үзидарә органында булу-булмавы хакында белешмәләре булмаса, бу хакта шулай ук гарызнамә җибәргән мәгълүматтан файдаланучыга гарызнамә теркәлгән көннән җиде көн эчендә хәбәр ителә.

2.13. Соратып алына торган мәгълүмат алу мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматлар рәтенә кертелгән очракта, гарызнамәгә җавапта мондый мәгълүмат алуны чикли торган актның төре, исеме, номеры һәм аны кабул итү датасы күрсәтелә. Соратып алына торган мәгълүматның бер өлеше алуы чикләнә торган мәгълүматлар рәтенә кертелгән, мәгълүматның калган өлешен алу мөмкин булган очракта, Дәүләт комитеты соратып алына торган мәгълүматны алуы чикләнгән мәгълүматтан башка гына бирә.

2.14. Дәүләт комитетына гарызнамә чит телдә кергән очракта, гарызнамә Дәүләт комитетында каралган тәртиптә карала.